Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы

Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№1 24.02.2015 ел

**Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге территориясендә 2015 елга наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында**

«Россия Федерациясенең 2020 елга кадәр Дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Президентының 09.06.2010 ел, № 690 Указы нигезендә, «наркотикларның, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» Россия Федерациясе Президентының 18.10.2007 ел, № 1374 Указы нигезендә, наркомания таралу куркынычы янавын киметү максатларында 2015 елга чаралар планы нигезендә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм наркотиклар куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар итә:

1.Савруш авыл җирлегенең 2015 елга наркотикларга каршы чаралар планын расларга.

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълумати стендларында һәм рәсми сайтында игълан итәргә: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Савруш авыл җирлеге
Башлыгы А.Г.Кузьмин.

Кушымта №1
Савруш авыл җирлеге
Башлыгы карарына

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы наркотикларга каршы комиссия составы**

Комиссия рәисе: Кузьмин Андрей Георгиевич Савруш авыл җирлеге башлыгы

Комиссия секретаре: Васильева Надежда Николаевна,

Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары

Комиссия әгъзалары: Хөснетдинов Руслан Гомәр улы, участок инспекторы

Россия Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы буенча ОП

Герасимова Ирина Алексеевна, директор

Иске Савруш төп мәктәбе

Федорова Мария Михайловна,

Иске Савруш ФАП мөдире

Кушымта

2

к Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты карары
№ 1 , 24.02.2015ел.

**2015 елга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планы**

Программаның төп чаралары булып:

- оештыру чаралары;

- наркоманияне профилактикалау системасы учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеге;

наркотиклар һәм психотроп матдәләрне дөрес кулланмауның тискәре нәтиҗәләрен профилактикалау;

- наркоманиягә каршы тору системасы учреждениеләренең матди-техник базасын камилләштерү;

эшчәнлекне мәгълүмат белән тәэмин итү

| №п/п | эчтәлек | Башкаручы | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Наркотикларга каршы комиссия утырышларын үткәрү | Антинаркотическая комиссия | Кварталга 1 тапкыр |
| 2 | Наркомания һәм наркоҗинаятьчелекне профилактикалау өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча норматив-хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу | Антинаркотическая комиссия | Кирәк булганда |
| 3 | Мәдәни-массакүләм һәм ял итү чаралары уздырылган урыннарда наркотикларның таралу фактлары турында мәгълүмат җыю, гомумиләштерү һәм анализлау. | Антинаркотическая комиссия | даими |
| 4 | Наркоманиягә каршы торуның агымдагы мәсьәләләрен, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән мәгълүматны яктырту өчен ММЧ вәкилләре белән аралашу. | Совет | Кирәк булганда |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | Китапханәләр, мәгариф учреждениеләре базасында наркомания, алкоголизм һәм ВИЧ-инфекция проблемалары буенча мәгълүмат банкын булдыру һәм саклау. | Антинаркотическая комиссия | даими |
| 6 | Тар профильле белгечләрне (психолог, нарколог, юрист һ. б.) җәлеп итеп, авыр тормыш хәленә эләккән яшүсмерләргә консультацияләр бирү | АНК, мәктәп | Кирәк булганда |
| 7 | Авыр тормыш хәлендә калган балаларны ачыклау, балигъ булмаганнарга карата мәрхәмәтсез мөгамәлә фактларын кисәтү, имин булмаган гаиләләрне ачыклау, балигъ булмаганнарны җинаять кылуга җәлеп итү фактларын ачыклау һәм кисәтү буенча даими рейдлар үткәрү. | АНК | Ай саен |
| 8 | Балаларны тәрбияләү һәм урнаштыруда практик ярдәм күрсәтү өчен ярлы гаиләләргә һәм социаль куркыныч гаиләләргә бару. | АНК | Ай саен |
| 9 | Яшүсмерләрнең кеше сәламәтлегенә тәмәке тарту, алкоголь, наркомания, ВИЧ-инфекциянең зарарлы йогынтысы турында мәгълүматлы булуларын мониторинглау. | Китапханә мәктәп | даими |
| 10 | Авыл китапханәсендә наркоманияне профилактикалау буенча чаралар үткәрү (мәгълүмат стендлары, укучылар конференцияләре). | Китапханә | Ноябрь |
| 11 | Наркомания һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча айлык үткәрү | Авыл җирлеге башкарма комитеты, АНК, мәктәп | Октябрь |
| 12 | "Музыка-да!" акция-концертын оештыру һәм үткәрү Наркотиклар юк!, Наркотикларсыз дөнья, протест акциясе "СПИД йокламый" | СДК, мәктәп | Апрель -Декабрь |
| 13 | Наркотиклы үсемлекләрне юк итү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы УУП<br><br>Участок вәкаләтлесе | Май -октябрь |
| 14 | Алкогольле продукция һәм сыра сату | АНК, РФ Эчке | Ай саен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белән шөгыльләнүче сәүдә нокталары буенча рейдлар үткәрү. | эшләр министрлыгының Аксубай районы УУП (полиция) | |
| 15 | Кичке вакытта дискотекаларны, яшьләр массакүләм чараларын тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы УУП (полиция) | Ай саен |
| 16 | 2016 елга АНК эш планын раслау. | АНК | Декабрь 2015ел |